| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

"21" сентябрь 2022 ел — № 1045

2022-2023 уку елында гомуми белем бирү оешмаларында баланслы кайнар туклануны оештыру турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, 2.3/2.4.3590-20 санитар – эпидемиологик кагыйдәләрне һәм нормаларны тормышка ашыру максатларында Норлат муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тулы күләмдә тукландыру һәм сәламәтлекләрен саклауны тәэмин итү максатында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. Төп туклыклы матдәләр буенча балансланган кайнар туклануны 2.4.5.2409-08 номерлы СанПиН нигезендә оештырырга.
3. Туклануны оештыруны регламентлаучы норматив-хокукый һәм инструктив – методик документларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

-гомуми белем бирү оешмаларында 2 тапкыр кайнар аш әзерләүне оештыруны контрольдә тоту;

- гомуми белем бирү оешмалары укучыларының кайнар ризык белән туклануын 100% тан ким булмаган дәрәҗәдә контрольдә тоту.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә кайнар туклану рационнарының Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән килештерелгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан эшләнгән ике атналык үрнәк менюсына таянырга.
5. Туклануны оештыру һәм сыйфатын контрольдә тоту чараларында ата-аналарны җәлеп итәргә.
6. Укучыларны ашату тәнәфесе 3,5 – 4 сәгатьтән артып киткәндә, шул исәптән ата-аналарның ирекле чаралары хисабына да, ике тапкыр кайнар аш белән тәэмин итүне арттыру буенча системалы эш алып барырга.

7. Алына торган продукциянең сыйфатын һәм йорт яны кишәрлекләрендә үстерелгән җиләк-җимеш культураларының, шул исәптән үсемлек стериннарын һәм җитештерелгән продукцияне карап тотуны җитештерү контроле программасын эшләргә; җитештерү контроле кысаларында сөт продукциясен лаборатор тикшерүне күздә тотарга.
8. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә әзерләгән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль заказчылары тарафыннан туклану продуктларын кабул итү регламентына таянырга.
9. Кайнар ризык белән туклануны оештыру өчен шәхси җаваплылыкны гомуми белем оешмалары директорларына йөкләргә.
10. Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру өчен җаваплы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге баш белгеченә, укучыларга социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – ЕГИССО) файдалану юлы белән, ЕГИССО операторлары билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә туклану турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.
11. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2022 елларда гомуми белем бирү оешмаларында балансланган кайнар ризык белән туклануны оештыру турында» 2021 елның 9 октябрендәге 1141 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Р. Р. Хәмзин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында баланслы кайнар туклану оештыру тәртибе турында нигезләмә

2022 ел

ЭЧТӘЛЕК.


1. Гомуми нигезләмәләр.........................................................................4 б.
2. Төп максатлар һәм бурычлар.................................................................4 б.
3. Укучыларның туклануын оештыруның гомуми ринциплары.....................5 б
4. Мәктәптә укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе ...........................6 б.
5. Кайнар туклануны оештыруны контрольдә тоту.........................................6 б.
6. Якларның җаваплылыгы..........................................................................7 б.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында рациональ туклануны оештыру тәртибен билгели һәм укучыларның туклануын оештыруга төп оештыру принципларын, кагыйдәләрен һәм таләпләрен билгели.

1.2. Нигезләмә укучыларның тулы канлы кайнар тукलануын оештыру, социаль ярдәм күрсәтү һәм балаларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү процессының уңайлы мохитен булдыру максатларында эшләнде.

1.3. Нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, санитар - эпидемиологик кагыйдәләр һәм СанПиН 2.3/2.4.3590-20 «Халыкның җәмәгать тукलануын оештыруга эпидемиологик - санитар таләпләр» нигезендә эшләнгән.

## 2. Укучыларның тукलануын оештыруның гомуми принциплары.

2.1. Укучыларны туклandыруны оештыру өчен түбәндәге юнәлешләр буенча санитар – гигиена нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры килгән махсус бүлмәләр (азык-төлек блогы) кулланыла:

- ашханәдә утырту урыннарының тиешле саны;
- технологик җиһазлар белән тәэмин итү;
- азык саклау өчен ярдәмче урыннар булу;
- кухня һәм ашханә савыт-сабасы, ашханә приборлары белән кирәкле күләмдә һәм СанПиН таләпләренә туры китереп тәэмин итү;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлдәге санитар нормаларның һәм кагыйдәләрнең башка таләпләренә туры килү.

2.2. Азык-төлек блогында түбәндәге документлар булырга тиеш:

- укучыларның фактик килүен исәпкә алу журналы;
- бозыла торган продукциянең бракеражы журналы;
- әзер кулинария продуктларының бракераж журналы;
- сәламәтлек журналы;
- суыткыч җиһазларның температура режимын исәпләү журналы;
- якынча 10 көнлек меню күчермәләре;
- көндәлек менюлар, әзерләнгән ризыклар өчен технологик карталар;
- азык-төлек продукциясенә керүче документлар ,азык-төлек продукциясенең сыйфатын раслаучы документлар (накладной, ярашлылык сертификатлары, сыйфат таныклыклары, ветеринария – санитария экспертизасы документлары һ. б.);
- фикерләр һәм тәкъдимнәр китабы.

2.3. Гомуми белем бирү учреждениесе администрациясе сыйныф җитәкчеләре белән берлектә түләүле яки түләүсез нигездә кайнар ашны оештыру максатыннан укучылар һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) белән оештыру һәм аңлату эшләрен башкара.

2.4. Мәктәп администрациясе укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән оештыру – идарә карарларын, сәламәт туклану принципларын һәм санитар – гигиена нигезләрен кабул итүне тәэмин итә.

2.5. Мәктәпләрдә туклану режимы Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган “Гомуми белем учреждениеләрендә туклануны оештыруга санитар – эпидемиологик таләпләр" 2.3/2.4.3648-20 номерлы СанПиН нигезендә билгеләнә.

2.6. Мәктәптә туклану эшләнә торган туклану рационы һәм әзерләнүче ризыкларның үрнәк менюсын һәм азык кыйммәтен төзүнең тәкъдим ителә торган формасы нигезендә эшләнгән якынча ун көнлек меню нигезендә оештырыла, шулай ук меню - ризыкларның рецептурасы турындагы күрсәткечләрне үз эченә алган өлешләп бүленеш нигезендә оештырыла.

2.7. Якынча меню мәктәп директоры тарафыннан раслана.

2.8. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру һәм тулыландыру өчен җаваплы зат булып тора. Мәктәп директоры боерыгы белән агымдагы уку елына җаваплы зат билгеләнә.

## 3. Мәктәптә укучыларны туклындыруны оештыру тәртибе.

3.1. 5-11 сыйныф укучыларын туклындыру түләүле һәм түләүсез оештырыла, башлангыч звено укучыларын туклындыру федераль бюджет хисабына оештырыла.

3.2. Көндәлек туклану рационнары менюлары гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе белән килешә, ашамлыклар һәм кулинария эшләнмәләре атамалары турында мәгълүматлар күрсәтелгән меню ашханәдә эленеп тора.

3.3. Озата баручы сыйныф җитәкчеләре, педагоглар ашханәгә йөрү режимын үтиләр, җәмәгать тәртибен саклыйлар һәм ашханә хезмәткәрләренә булышалар, укучыларның ашау алдыннан шәхси гигиенасын контрольдә тоталар.

3.4. Азык-төлек продуктларының һәм азык-төлек чималының, әзер кулинария продукциясенең сыйфатын, аш әзерләү рецептураларын һәм технологик процессларны үтәүне гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе, туклануны оештыру өчен җаваплы зат һәм/яки шәфкать туташы (шәһәр мәктәпләрендә), ФАПларда шәфкать туташы (килешү буенча) башкара.

3.5. Түләүсез туклану өчен укучылар контингентын билгеләү тәртибе.

3.5.1. Укучылары булган гаиләләргә адреслы, максатчан ярдәм күрсәтү максатыннан, ташламалы категорияләр билгеләү өчен түләүсез туклану хокукы бирелә. Ташламалы категорияләр:

-3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр;

- аз керемле гаиләләр;

- үз составында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган гаиләләр;

- үз составында инвалид балалары булган гаиләләр;

- ятим балалар.

## 4. Мәктәптә тукlануны оештыруны контрольдә тоту.

4.1 Туклануны оештыруны, санитар – эпидемиологик нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәүне, мәктәптә сатыла торган чимал һәм әзер продукциянең сыйфатын контрольдә тоту Роспотребнадзор органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Учреждениедә мәктәп укучыларын тукландыруны оештыруның агымдагы контролен туклануны оештыру өчен җаваплы кеше, мәктәп советы һәм ата-аналар комитеты вәкилләре, мәктәпнең башлангыч профсоюз оешмасы вәкилләре, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге белгечләре башкара.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Гомуми белем бирү учреждениесе администрациясе җаваплы:

- гамәлдәге законнар нигезендә укучыларның төп туклыклы матдәләрдән торган баланслы кайнар туклануын оештыру;
- Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе белән килештерелгән ассортимент исемлеге нигезендә буфет продукциясен сату;
- туклануны оештыру мәсьәләләренә һәм бирелә торган иртәнге һәм төшке ашларның хакына кагылышлы барлык үзгәрешләр турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) үз вакытында хәбәр итү.

5.2. Мәктәп ашханәләре кайнар ризыкның сыйфаты өчен җаваплы.

5.3. Укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) түләүле туклануны оештыру шартларын үтәү өчен җаваплы.